БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«25» 08 2025 ел

**КАРАР**

№ 231

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2023 елның 27 октябрендәге «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында бушлай туклану белән тәэмин итү тәртибен раслау турында»гы 271 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Президентының 2024 елның 23 гыйнварындагы «Күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында»гы 63 номерлы Указы нигезендә Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Балтач район башкарма комитетының 2023 елның 27 октябрендәге «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы гомуми белем оешмаларында бушлай туклану белән тәэмин итү тәртибен раслау турында»гы 271 номерлы карарына, түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1.3 пунктының 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 5 һәм аннан күбрәк баласы булган гаиләләрдәге балаларга, гаиләдәге өлкән бала 18 яшькә җиткәнче яисә белем бирү оешмасында көндезге формада белем алган очракта - 23 яшькә җиткәнче; күпбалалы гаилә таныклыгы күчермәсен, һәр баланың туу турында таныклыгы күчермәләрен һәм уку урыныннан белешмә тапшырып, ата-ананың (законлы вәкилләренең) язма гаризасы нигезендә».

1.2. 1.3 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган һәм опекада торучы балаларга, законлы вәкилләрнең язма гаризасы нигезендә опека һәм попечительлекне раслау документының күчермәсен һәм балаларның туу турында таныклыкларының күчермәләрен тапшырып,».

1.3. Түбәндәге эчтәлекле 1.4.пункты өстәргә:

«1.4. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гомуми белем оешмаларында белем алучы, өч һәм дүрт баласы булган күпбалалы гаиләләрдәге балаларга - өлкән бала 18 яшькә җиткәнче, яисә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада көндезге формада белем алган очракта - 23 яшькә җиткәнче, кайнар туклану өчен түләүнең 50% ы күләмендә социаль ярдәм чарасы билгеләргә, күпбалалы гаилә таныклыгы күчермәсен һәм һәр баланың туу турында таныклык күчермәләрен тапшырып, ата-ананың (законлы вәкилләрнең) язма гаризасы нигезендә».

2. Әлеге карарның 2025 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата гамәлдә булуын билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты житәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) һәм «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов